# Галләмов Әхәт Мөэмин улы



**21.01. 1921 - Кодаш авылында туа.**
**09.09.1940 - Кызыл Армиягә чакырыла.**
**1941- 1942 еллар, август - Чернигов хәрби-инженер училищесы курсанты.**
**1942 ел, август - Урал хәрби округының инженер-мина бригадасы.**
**1943 ел, апрель - 3 нче Белорус фронтында; Орша юнәлешендәге сугышларда, Смоленск, Березино, Борисов, Минск, Лида, Гродно шәһәрләрен азат итүдә катнаша һәм Көнчыгыш Прусссиягә кадәр барып җитә. Кенигсберг өчен сугышларда яралана. Чехословакия, Венгрия җирләрен фашист илбасарларыннан азат итүдә катнаша.**
**1948 ел -Төньяк Корея чигенә җибәрелә, аннары 12 ел Ерак Көнчыгыш хәрби округында хезмәт итә.**
**Сугышчан бүләкләре: 2 Кызыл Йолдыз ордены, 2 II дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм күпсанлы медальләре.**
**Хәрби хезмәтен полковник дәрәҗәсендә тәмамлый.**
**1990 ел - Бөгелмә шәһәренең Мактаулы гражданины.**
**2005 елда 84 яшендә вафат була.**

# Кодашым

Әхәт Галләмов

*“Кодаш” дисәм күз алдымда*
*Гаҗәеп яшел таулар,*
*Елгасына сакчы сыман*
*Торучы биек ярлар.*
*Уйсу җирдә күкрәп үскән*
*Шул чаклы бөдрә таллар!*
*Таулар аша офыклардан*
*Чакыра алсу таңнар.*
*“Кодаш” дисәм үргә менәм,*
*Таулар өстендә урман*
*Урман эче печән, җиләк...*
*Бәрәкәт белән тулган.*
*Чыксам басу- кырларыңа*
*Салкын чишмәләр күрәм.*
*Сусавымны басар өчен*
*Шул чишмәләргә киләм.*
*Авылым тора күз алдымда*
*Таудан карагач менеп.*
*Гел кайтып- күреп торсам да,*
*Һаман сагынам кебек.*



# Сынатмады татар егетләре

*Кырык бердә кара болыт кебек*

*Басып* керде *фашист илләргә.*

*Кичекмәстән без дә күтәрелдек,*

*Соры шинель салып иңнәргә.*

*Сынатмады татар егетләре,*

*Батырларча утка керделәр.*

*Курку белмәс арысланнар кебек*

*Фашистларны тетеп йөрделәр*

*Истән чыгармагыз батырларны,*

*Даны китсен ерак илләргә.*

*Һәйкәл булсын сезгә шигъри сүзем,*

*Яуда үлгән батыр ирләргә.*

## Заһит Сарим улы Әхмәтшин



**II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, “За победу над Японией”, Жуков медальләре иясе, 1944-1951 елларда армия сафларында хезмәт иткән сугыш ветераны**

# *Нуретдинов Галим Гыйләҗ улы (1917-1995)*



**Фашист илбасарлары илебезгә басып кергәндә ул, яңа гына хәрби хезмәттән кайтып, туган авылы Кодашта бригадир булып эшли башлый.**

**1941, август – элек үзе хезмәт иткән Ленинградтагы полкка эләгә.**

**Фашистлар бертуктаусыз ут яудыра. Аларның бер взводка якын солдаты бар. Ә рядовой Галим Нуретдинов бары тик командиры лейтенант Әбделханов белән генә кала. Егетнең кулыннан бер генә фашист та ычкына алмый.**

**Галим Гыйләҗ улы шушы батырлыгы һәм үз командирын коткарып калганы өчен I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.**


Фронт хакыйкате

**20 май 1944 ел – “Фронт хакыйкате” газетасындагы мәкалә**



# *Зиятдинов Гарәф Зиятдин улы*
# *1921-1990*




**1921 елда Кодаш авылында туа.**
**1941 елның апреленнән 1946 елның 5 июленә кадәр Совет Армиясендә хезмәт итә.**

**Хәрби бүләкләре:**
**Медаль «За боевые заслуги»**
**Медаль “За отвагу”**
**Медаль “За оборону Ленинграда”**
**Медаль “За Победу над Германией”**
**Медаль “За взятие Берлина”**


Гвардии Ефрейтор
Зиатдинов Гараф Зиатдинович.
Приказом Верховного Главнокомандующего Маршала Советского Союза товарища Сталина от 19. Января 1944 г. №
за Освобождение г. Красное Село
всему личному составу нашего соединения, в том числе и Вам, принимавшему участие в боях, ОБЪЯВЛЕНА БЛАГОДАРНОСТЬ.
КОМАНДИР ЧАСТИ (подпись)
Мы в битвах решаем судьбу поколений,
Мы к славе отчизну свою поведем!


„ЗА ПОБЕДУ НАД ГЕРМАНИЕЙ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941—1945 гг.“
УДОСТОВЕРЕНИЕ
За участие в Великой Отечественной войне
Гвардии ефрейтору Зиатдинову Гарафу Зиатдиновичу
Указом Президиума Верховного Совета СССР от 9 мая 1945 года награжден медалью „За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941—1945 гг.“
От имени Президиума Верховного Совета СССР медаль вручена ... 1946 г.

**Туган илне саклап,**
**яу кырларыннан исән-имин кайтып, гомерен Кодаш авылы мәктәбендә 1952-1983 нче елларда яшь буынны тәрбияләүгә биргән.**



# *Мөлеков Фәрит Галим улы (1924-1978)*



**1924 ел – Кодаш авылында туа.**
**1942 ел - сугышка алалар.**
**Махсус әзерлек үткәннән соң аны танкка каршы ата торган 45 миллиметрлы пушканың төзәп торучысы итеп билгеләп, фронтка озаталар.**
**Икенче Белоруссия фронтында станоклы пулеметның төзәп торучысы булып сугыша.**
**1944 ел, апрель – рядовой Кашин белән бергә күзәтү пунктын саклыйлар.**
**Смоленск, Минск, Вильнюс шәһәрләрен азат итүдә катнаша.**
**Сугышчан бүләкләр: “Батырлык өчен” медале, өлкән сержант званиесе бирелә, Дан оренына лак була.**
**Фәрит абый фоторәсемгә бик оста төшерүче була. Ул төшергән сурәтләр Кодаш авылының һәр йортында һәм мәктәп музеенда бик күп.**







# *Галиев Хөснетдин Гали улы (1919 – 2018)*

**1939 елның 22 октябрь Совет Армиясенә алына.**
**1939 -1941 елның маена кадәр Чкалов (хәзерге Оренбург) “Стрелковое пулетмётное училище”сендә укый.**

**1941 елның  июнендә лейтенант Галиев Киев военный округына җибәрелә.**

**Иң беренче көннән үк лейтенант Галиев- взвод командиры.**
**1941нче елның 22 июнен (сугышның беренче көнен) Киев шәһәрендә каршылый ул. Житомир, Киев, Чернигов, Харьков, Полтава өлкәләре территориясендәге сугышларда катнаша.**
**1942 нче елның май аенда Полтава өлкәсендә әсирлеккә  төшә.Сугыш беткәч, тулысынча реабилитацияләнеп, Союзга кайта.**
**II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, күпсанлы медальләр кавалеры.**
**Хезмәт Кызыл байрагы ордены, медальләр һәм бик күп мәртәбә Мактау грамоталары белән бүләкләнә.**

